Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Иске Иштирәк авыл җирлегенең
Ялтау авылы гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, аерым алганда:
Ялтау торак пункты чикләрендә янгын гидранты урнаштыру
«РИЗА» «КАРШЫ».
соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә кеше 77 кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 42.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 42 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлегенең Ялтау авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Иштирәк авыл җирлеге составына Ялтау авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Иштирәк авыл җирлеге Ялтау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум

күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, аерым алганда:

Ялтау торак пункты чикләрендә янгын гидранты урнаштыру

сораулары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15 йорт; Ялтау авылы, Нагорная урамы, 38 йорт; Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы “Иске Иштирәк авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Вәлиәхмәтов